Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июнь 2015 ел № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында

«Терроризмга каршы тору турында " 06.03.2006 ел, № 35-ФЗ Федераль закон нигезендә, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, халыкны террорчылык актларыннан яклау, кешеләр күп була торган объектларны саклау максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләрнең һәм объектларның (территорияләрнең) массакүләм саклануы урыннарының һәм объектларының (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланганлыгы таләпләрен һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортларын раслау турында» 25.03.2015 ел, № 272 карарын үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясе чикләрендә кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2 нче кушымта нигезендә кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләүне уздыру өчен кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзергә.
3. Ведомствоара комиссия 2015 елның 1 июленә кадәр кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләүне үткәрергә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча куркынычсызлык паспортын төзергә тиеш.
4. . Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Д. Ә. Газизов